**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 7 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 90 мин.

## I бүлек

Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләр янына авторларын язып чыгыгыз

1. “Эшкә өндәү” шигыре ______________________________
2. “Татар байрагы” шигыре ______________________________
3. “Алмачуар” хикәясе ______________________________
4. “Сагыну” нәсере ______________________________
5. “Кем җырлады” хикәясе ______________________________

## II бүлек

Мәсәл жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## III бүлек

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

а) Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;

1. Шигырьнең авторын һәм исемен күрсәтегез

2. Шигырьнең калган ике юлын хатасыз язып бетерегез

3. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез

б) Дүрт йөз ел буе
Ниләр күрмәдек,
1.Шигырьнең авторын һәм исемен күрсәтегез

2. Шигырьнең калган ике юлын хатасыз язып бетерегез

3. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез

Дуслык турында нинди мәкаль-әйтемнәр беләсез. 10 мисал языгыз

## IV бүлек

| Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез |
|---|

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләре-безнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

1. Әсәрнең авторын языгыз ______________________________________
2. Әсәрнең жанрын билгеләгез__________________________________
3. “Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!” җөмләсенең нигә еш кабатлануынаңлатыгыз_______________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

4. Әлеге сүзләргә бәйләп, кабатлау, чагыштыру, сынландырулар да кулланып, туган ягыгызны ярату хисләре турында кыска инша языгыз.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

_

## Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 8 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары

Үткәрү вакыты 90 мин.

## I бүлек

| Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләр янына авторларын язып чыгыгыз |
|---|

1. “Туган ягым – яшел бишек” повесте ______________________________
2. “Бер үгет” шигыре ____________________________________
3. “Сөннәтче бабай” повесте _____________________________________
4. “Беренче театр” комедиясе _____________________________________
5. “Ак чәчәкләр” романы _____________________________________

## II бүлек

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.
Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.
Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!
Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр,
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.
Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең, маяк булып
Үзеңнән соң килгән буынга.
Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

1. Шигырьнең авторын һәм исемен күрсәтегез
___________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

2. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

3. Шигырьдә кулланылган троплар, стилистик фигураларны күрсәтегез
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

## III бүлек

| Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез. |
|---|

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

## Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 9 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары

<u>Үткәрү вакыты 90 мин.</u>

## I бүлек

| Дөрес җавапларны билгеләгез |
|---|

1.“Үлемнән көчлерәк” (Самат Шакир) әсәренең жанры - ___________________
2. “Җомга көн – кич белән” әсәрен иҗат иткән язучы -___________________

3. Проза төренең жанрларын билгеләп, дөрес җавапны түгәрәккә алыгыз:
а) шигырь, хикәя, драма ә) трагедия, комедия, драма
б) роман, повесть, хикәя в) әкият, табышмак, җыр

## II бүлек

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

Яшәү чыганагы – Кояш нурын,
Җир җылысын саклап үзендә,
Күкрәкләргә терәп кисәр икмәк
Һәр табынның тора түрендә.
Икмәк - игенченең җан җылысы,
Җир-анага кадер-хөрмәте.
Яшәү тамыры улһәр йөрәкнең,
Әти-әни, Ватан һәм дә икмәк!
Бу сүзләрдә – тормыш мәгънәсе.
Бәхет, хезмәт, ирек, яшәү яме –
Шул сүзләргә бәйле һәммәсе.

1. Шигырьнең авторын һәм исемен күрсәтегез_________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

2. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез ____________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_____________________________________________________________

3. Шигырьдә образ, хис тудыруда ярдәм иткән троплар, стилистик һәм лексик чараларны табыгыз ________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

## III бүлек

Хикәя жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

## IV бүлек

| IV бүлек биремнәренә җавап языгыз |
| --- |

...Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газинурлар, Матросовлар шикелле күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы, әллә үзең ач чакта соңгы икмәк сыныгың белән бүлешүме? Кешеләр төрле-төрле булган кебек, батырлык та күптөрле шул.

Берәүләрне тормыш гомергә бер генә сыный. Кеше дөнья зилзиләләренә каршы үзенең кечкенәдән үк җыелып килгән гайрәтен, ана сөте белән кереп, тамырларына таралган көчен куя. Куя да өстенә ябырылып килгән бөтен авырлыкларны бер селтәнүдә юкка чыгара. Шул мизгелдә каушап калмаганнарны батыр диләр.

Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный. Алар күкрәкләре белән дошманның ялкын чәчеп торган дзотларын япмыйлар, галәм биеклекләренә күтәрелеп, дөньядагы барлык кешеләрнең карашларын үзләренә юнәлтмиләр. Туктаусыз тамып торган тамчыдай, сиздерми генә, шау-шуларсыз гына эшлиләр. Беренче тамган тамчыны һичкем игътибарга алмый. Тама-тама ташны тишеп чыккач кына тамчыга сокланалар. Ә ташны тишеп чыкканчы, ай-яй озак тамасы бар!...

Ничә язлар көтәсе бар, ничә кышлар үтәсе бар...

1. Әсәрнең исемен, авторын языгыз
2. Әсәрнең жанрын билгеләгез ___________________________________
3. “Батырлык” сүзе үз эченә нинди сыйфатларны ала? Санагыз_

4. “Батырлык” сүзенә бәйләп, троплар кулланып, кыска инша языгыз.

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 10 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 120 мин.

**I бүлек**

| Бирелгән сорауларга дөрес җавапларны күрсәтегез |
|---|

1. **Болгар чорында иҗат иткән язучы:**
а) Кол Гали
ә) Сәйф Сараи
б) Фатих Кәрими
в) Мәүлә Колый

**2. Ничәнче елдан болгарларда, рәсми рәвештә, ислам дине гамәлгә кертелә:**
а) 737
б) 922
в) 911

**3. Ислам дине белән бергә төркиләргә үтеп кергән һәм иң озак кулланышта булган графика:**
а) гарәп графикасы
ә) уйгур графикасы
б) рун алфавиты

**II бүлек**

| Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез |
|---|

Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган хан тагы
Кан тагы булып әверелде;
Хан сарае камалды.

Кырым, Казан, Аждаркан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

1. Әсәрнең исемен һәм жанрын күрсәтегез.
2. Төп геройларны санап чыгыгыз
3. Әсәр турында белгәннәрегезне языгыз.

## III бүлек

**Г.Исхакый иҗатына бәйле сорау-биремнәргә җавап бирегез**

1. Г.Исхакыйның “Ул әле өйләнмәгән иде” повестендагы Анна Васильевнага характеристика бирегез.

2. Повесть герое Шәмсинең эчке каршылыгы нидән гыйбарәт?

3. “Ул әле өйләнмәгән иде” повестеның яңалыгын нидә? Ничек уйлыйсыз, әсәр бүген дә заманча яңгырашлымы?

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

## IV бүлек

| IV бүлек биремнәренә җавап языгыз |
| --- |

“Тәрбия кыйлмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак вә төзәтмәк, вә, хайванидан чыгарып, инсаният чыгарып, инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә үгрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер. Ошбу китабта зикер кыйлыначак хикәятләр, вәгазьләр вә нәсихәтләр һәммәсе, вә бу рисаләнең һәрбер кәлимәсе − бер тәрбиядер, шул җәһәттән “...........” дип ат бирдек.

1. Хезмәтнең исемен, авторын языгыз_________________________
________________________________________________________________
2. Ни өчен бу авторны “мәгърифәтче галим” дип атыйбыз. Аңлатыгыз.

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

3. “Тәрбия”, “белем” төшенчәләрен кулланып, троплар, стилистик чаралардан да файдаланып, кыска инша языгыз.

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 11сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 120 мин.

## I бүлек

| Бирелгән сорауларга дөрес җавапларны күрсәтегез |
|---|

1. **“Мәхәббәт тәүбәсе” (Һ.Такташ) әсәренең жанры:**
   а) роман ә) поэма
   б) драма в) шигырь

2. **Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучы:**
   а) Фәнис Яруллин
   ә) Ф.Әмирхан
   б) Фатих Кәрим
   в) Хәсән Туфан

3. **Фатих Кәримнеке булмаган әсәр:**
   а) Разведчик язмалары
   б) Сибәли дә сибәли
   в) Кошчык

## II бүлек

| Роман жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. |
|---|

________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
____________________________________________________________

## III бүлек

| М.Мәһдиев иҗаты белән бәйле сорау-биремнәргә җавап языгыз |
|---|

1. М.Мәһдиевнең дүрт әсәрен санагыз

2. Ф.Миңнуллин М.Мәһдиев иҗатына бәя биреп, "яшьлеген сагынучы әдип", дип язды. Тәнкыйтьченең бу фикерен ничек аңлыйсыз?

3. "Бәхилләшү", яки "Кеше китә – җыры кала" әсәрендә сурәтләнгән чорга бәя бирегез

4. Әдипнең күп әсәрләре "тартмалы композиция"гә нигезләнгән. Әлеге төшенчәне аңлатыгыз

5. "Кеше китә – җыры кала" дигән исемгә салынган мәгънәне аңлатыгыз

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

“Юк, Сәрвәр, безгә кавышу насыйп булмас. ... Безне аерырлар. Мин төшемдә шулай күрдем. Өч тапкыр шул бер үк төшне күрдем. Көзге караңгы төн, имеш. Күктәге йолдызлар шундый яктылар, имеш. Бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә һәркайсы үзенә берәр йолдыз алганнар икән. Син дә шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде. Тагын бик күп, бик күп егетләрнең йолдызлары сүнеп, күк йөзе корымлы кара таба төсле караңгыланып, каралып калды.

Сәрвәр *(елап)*. Җитәр, җитәр, җитәр... Юк, юк, бу — ялган төш, бу дөрес түгел”.

1. Драманың авторын һәм исемен күрсәтегез________________________

____________________________________________________________________

2. Төш күрүченең исемен атагыз. Сюжет сызыгында төш күрү вакыйгасының урыны нинди? Сүз нәрсә турында бара. Аңлатыгыз.

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

3. Сәрвәр, Исмәгыйльгә хас сыйфатларны санагыз һәм шуңа бәйләп төп идеяне ачыгыз

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

## IV бүлек

| IV бүлек биремнәренә җавап язагыз |
|---|

X. Туфанның “Ромашкалар” шигырендә кулланылган метафораны табыгыз. Ул ни өчен кулланылган, аңлатыгыз.

Юк ромашка,
Минем йөрәкнең
Януларын баса алмыйсың
Сөя әле, сагына һаман, дип,
Алдыйсың ич мине, алдыйсың.

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

## V бүлек

11 сыйныфта укыган әсәрләрдән мисаллар китереп, ике яшь кеше арасындагы мәхәббәт хакында фикерләрегезне инша итеп языгыз